ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.12.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3376**

2026 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның баланслы кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына дәүләт гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укучыларны, шулай ук дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү хакы күләмен раслау турында» 2025 елның 03 октябрендәге 786 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белемнең уку-укыту программалары буенча бер укучыга кайнар ризыкның уртача бәясен раслау турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 726 нчы номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче укучылар өчен һәр уку көнендә 77 сум 76 тиенгә бушлай туклануны оештырырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклandыруга Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен һәр уку көненә 10 сум 70 тиен итеп билгеләргә.

3. Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче һәрбер укучыга һәр уку көненә Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 76 сум 08 тиен итеп түбәндәге категориядәгеләргә билгеләргә:

-үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләдәге укучыларга;

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы, ятим балалар һәм ата - ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Норлат балалар йорты» дәүләт белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләргә.

4. Җайлаштырылган уку-укыту программалары буенча белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәрбер укучыга һәр уку көненә Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 114 сум 05 тиен итеп билгеләргә.

5. Һәрбер 1 – 11нче сыйныф укучысына һәр уку көненә махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаилә әгъзалары арасыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ихтыярый рәвештә үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категория гражданнарның гаилә әгъзаларына Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 114 сум 05 тиен итеп билгеләргә.

6. 2026 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә, «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку чорында туклану белән тәэмин итүне оештыруга бәйле чыгымнар буенча финанслауны гамәлгә ашырырга.

7. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар законлы көченә 2026 елның 12 гыйнварыннан керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин